**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Порядка назначения Раисом Республики Татарстан временно исполняющего полномочия главы муниципального образования Республики Татарстан

В соответствии с частями 6 и 22 статьи 19 и частью 16 статьи 21 Федерального закона от 20 марта 2025 года № 33-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в единой системе публичной власти» **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемый Порядок назначения Раисом Республики Татарстан временно исполняющего полномочия главы муниципального образования Республики Татарстан.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его официального опубликования.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
25 июня 2026 года
№ 508

УТВЕРЖДЕН
Указом Раиса
Республики Татарстан

от «25» июня 2026 года

№ 508

# ПОРЯДОК
## назначения Раисом Республики Татарстан временно исполняющего полномочия главы муниципального образования Республики Татарстан

1. Настоящий Порядок устанавливает процедуру назначения Раисом Республики Татарстан временно исполняющего полномочия главы муниципального образования Республики Татарстан (далее – муниципальное образование) в случаях, предусмотренных частью 6 статьи 19 и частью 16 статьи 21 Федерального закона от 20 марта 2025 года № 33-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в единой системе публичной власти» (далее – случаи, предусмотренные Федеральным законом).

2. В течение двух дней со дня наступления в отношении главы городского или сельского поселения одного из случаев, предусмотренных Федеральным законом, за исключением случая, когда указанное лицо одновременно замещает должность главы муниципального района, глава муниципального района, в состав которого входит соответствующее городское или сельское поселение, направляет уведомление об этом Раису Республики Татарстан.

3. В уведомлении указываются:

а) один из случаев, предусмотренных Федеральным законом, являющийся основанием для назначения Раисом Республики Татарстан временно исполняющего полномочия главы городского или сельского поселения, а также дата возникновения соответствующего случая (с приложением документа, подтверждающего его наступление (при наличии);

б) предложение о кандидате на должность временно исполняющего обязанности главы городского или сельского поселения.

4. При наступлении одного из случаев, предусмотренных Федеральным законом, в отношении главы муниципального района или городского округа Раис Республики Татарстан самостоятельно определяет кандидата на должность временно исполняющего обязанности главы соответствующего муниципального образования либо по его поручению Комиссия по кадрам Совета по вопросам кадровой политики при Раисе Республики Татарстан (далее – Комиссия по кадрам Совета) представляет предложение о кандидате.

5. Комиссия по кадрам Совета в течение трех дней со дня поступления на имя Раиса Республики Татарстан уведомления, предусмотренного

в пункте 2 настоящего Порядка, вправе представить Раису Республики Татарстан предложение о кандидате.

6. При принятии решения о кандидате Раис Республики Татарстан учитывает предложения, внесенные в соответствии с подпунктом «б» пункта 3 и пунктом 5 настоящего Порядка, сохраняя за собой право окончательного выбора кандидата.

7. К уведомлению, предусмотренному пунктом 2 настоящего Порядка, в целях осуществления проверки соответствия кандидата предъявляемым к нему законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан требованиям прикладываются следующие документы:

а) заявление кандидата в письменной форме о согласии на временное исполнение полномочий главы муниципального образования с обязательством в случае его назначения прекратить деятельность, несовместимую со статусом главы муниципального образования;

б) согласие кандидата на обработку персональных данных, оформленное в соответствии с требованиями Федерального закона от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных»;

в) заполненная и подписанная кандидатом анкета по форме, утвержденной Указом Президента Российской Федерации от 10 октября 2024 года № 870 «О некоторых вопросах представления сведений при поступлении на государственную службу Российской Федерации и муниципальную службу в Российской Федерации и их актуализации»;

г) копия паспорта кандидата или иного документа, удостоверяющего личность кандидата, заверенная кадровой службой (должностным лицом, ответственным за ведение кадровой работы) органа местного самоуправления муниципального образования (далее – кадровая служба);

д) копия трудовой книжки кандидата, заверенная кадровой службой, и (или) сведения о трудовой деятельности кандидата, оформленные в установленном законодательством порядке, за исключением случаев, когда служебная (трудовая) деятельность осуществляется впервые;

е) копии документов об образовании и о квалификации кандидата, заверенные кадровой службой;

ж) копии документов воинского учета – для кандидата, пребывающего в запасе или подлежащего призыву на военную службу, заверенные кадровой службой;

з) заключение медицинской организации об отсутствии у кандидата заболевания, препятствующего поступлению на государственную гражданскую службу Российской Федерации и муниципальную службу или ее прохождению;

и) справка о наличии (отсутствии) судимости и (или) факта уголовного преследования либо о прекращении уголовного преследования кандидата.

8. Администрация Раиса Республики Татарстан осуществляет проверку соответствия кандидата предъявляемым к нему законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан требованиям, в том числе путем направления запросов в соответствующие государственные органы и иные организации в установленном порядке.

Администрация Раиса Республики Татарстан вправе получать у кандидата пояснения по представленным в отношении него документам и сведениям.

9. В случае, если в процессе проверки установлено, что у кандидата отсутствуют ограничения пассивного избирательного права в соответствии с законодательством об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации (далее – ограничения пассивного избирательного права), Руководитель Администрации Раиса Республики Татарстан представляет Раису Республики Татарстан информацию о кандидате для согласования, за исключением случая, когда кандидат определен Раисом Республики Татарстан самостоятельно.

10. В случае несогласования кандидата Раисом Республики Татарстан либо в случае, если в процессе проверки установлено, что кандидат имеет ограничения пассивного избирательного права, Администрация Раиса Республики Татарстан уведомляет главу муниципального района, направившего Раису Республики Татарстан уведомление, либо Комиссию по кадрам Совета об отклонении представленного кандидата.

11. В случае отклонения представленного кандидата глава муниципального района или Комиссия по кадрам Совета вносит новое предложение о кандидате.

12. В случае согласования Раисом Республики Татарстан кандидата, представленного в соответствии с пунктом 9 настоящего Порядка, либо в случае, если в процессе проверки кандидата, определенного Раисом Республики Татарстан, установлено отсутствие ограничений пассивного избирательного права, Администрация Раиса Республики Татарстан подготавливает в установленном порядке проект указа Раиса Республики Татарстан о назначении временно исполняющего полномочия главы муниципального образования.

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую тәртибен раслау турында**

«Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 6 һәм 22 өлешләре һәм 21 статьясының 16 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 25 июнь
№ 508

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның « 25 » июнендәге
508 номерлы Указы белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую**
**ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге Тәртип нигезендә «Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 6 өлеше һәм 21 статьясының 16 өлешендә каралган очракларда (алга таба – Федераль законда каралган очракларда) Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую процедурасы билгеләнә.

2. Шәһәр яисә авыл җирлеге башлыгына карата Федераль законда каралган очракларның берсе барлыкка килгән көннән ике көн эчендә, әлеге зат бер үк вакытта муниципаль район башлыгы вазыйфасын биләгән очрактан тыш, аның составына тиешле шәһәр яисә авыл җирлеге кергән муниципаль район башлыгы бу турыда Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәрнамә юллый.

3. Хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан шәһәр яисә авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую өчен нигез булып торган Федераль законда каралган очракларның берсе, шулай ук әлеге очрак барлыкка килү датасы (әлеге очрак барлыкка килүне раслый торган документны теркәп (булган очракта);

б) шәһәр яисә авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы вазыйфасына кандидат турында тәкъдим.

4. Муниципаль район һәм шәһәр округы башлыгына карата Федераль законда каралган очракларның берсе барлыкка килгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе тиешле муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы вазыйфасына кандидатны мөстәкыйль рәвештә билгели яисә аның күрсәтмәсе буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советының кадрлар буенча комиссиясе (алга таба – Советның кадрлар буенча комиссиясе) кандидат турында тәкъдим бирә.

5. Советның кадрлар буенча комиссиясе Татарстан Республикасы Рәисе исеменә әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган хәбәрнамә килгән көннән өч көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенә кандидат турында тәкъдим бирергә хокуклы.

6. Кандидат турында карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Рәисе, кандидатны сайлау буенча үзенең хәлиткеч карар кабул итү хокукын саклаган хәлдә, әлеге Тәртипнең 3 пункты «б» пунктчасы һәм 5 пункты нигезендә бирелгән тәкъдимнәрне исәпкә ала.

7. Кандидатны Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә аңа карата куелган таләпләргә туры килүен тикшерү максатында әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган хәбәрнамәгә түбәндәге документлар теркәп бирелә:

а) кандидат муниципаль берәмлек башлыгы итеп билгеләп куелган очракта, аның муниципаль берәмлек башлыгы статусында рөхсәт ителмәгән эшчәнлеген туктатачагы турында йөкләмәсен алып, муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкарырга ризалык белдерелгән язма гаризасы;

б) кандидатның «Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы;

в) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә һәм Россия Федерациясе муниципаль хезмәтенә кергәндә белешмәләр тапшыру һәм аларны актуальләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2024 елның 10 октябрендәге 870 номерлы Указы нигезендә расланган форма буенча тутырылган һәм кандидат тарафыннан кул куелган анкета;

г) кандидатның паспортының яисә кандидатның шәхесен таныклый торган башка документының муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте (кадрлар эшен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи заты) (алга таба – кадрлар хезмәте) тарафыннан таныкланган күчермәсе;

д) хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр башкарылган очраклардан тыш, кандидатның хезмәт кенәгәсенең кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе һәм (яисә) кандидатның хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;

е) кандидатның белеме һәм квалификациясе турында документларның кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;

ж) запаста булган яисә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле кандидат өчен – хәрби исәпкә кую турында документларның кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;

з) кандидатның Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә һәм муниципаль хезмәткә керүенә яисә аны башкаруына комачаулый торган авыруы булмавы турында медицина оешмасының бәяләмәсе;

и) кандидатның суд җаваплылыгына һәм (яисә) җинаять кылган өчен җаваплылыкка тартылуы (тартылмавы) яисә аңа карата җинаять эшенең туктатылуы турында белешмә;

8. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе кандидатның Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары

нигезендә аңа карата куелган таләпләргә туры килүен, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт органнарына һәм башка оешмаларга соратулар җибәрү юлы белән дә, тикшерә.

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе кандидаттан аңа мөнәсәбәтле бирелгән документлар һәм белешмәләр буенча аңлатмалар алырга хокуклы.

9. Тикшерү барышында Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында законнар нигезендә кандидатның пассив сайлау хокукына карата чикләүләр (алга таба – пассив сайлау хокукына карата чикләүләр) булмавы билгеләнгәндә, кандидат Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнгән очрактан тыш, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кандидат турында мәгълүматны килештерү өчен Татарстан Республикасы Рәисенә бирә.

10. Кандидатны Татарстан Республикасы Рәисе хупламаган яисә тикшерү барышында кандидатның пассив сайлау хокукына карата чикләүләр булуы ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәрнамә юллаган муниципаль район башлыгына яисә Советның кадрлар буенча комиссиясенә тәкъдим ителгән кандидатны кире кагу турында хәбәр юллый.

11. Тәкъдим ителгән кандидат кире кагылган очракта, муниципаль район башлыгы яисә Советның кадрлар буенча комиссиясе кандидат турында яңа тәкъдим кертә.

12. Әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә тәкъдим ителгән кандидат Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан хупланган яисә тикшерү барышында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнгән кандидатның пассив сайлау хокукына карата чикләүләр булмавы ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручыны билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Рәисе указы проектын әзерли.